КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1073

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче; 2020 ел, 24 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 31 май, 422 нче; 2022 ел, 22 февраль, 151 нче; 2022 ел, 9 июль, 660 нчы; 2022 ел, 15 декабрь, 1339 нчы; 2023 ел,

20 март, 298 нче; 2023 ел, 11 июль, 814 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык).»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«субсидия алучы Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

сайлап алуда катнашучы муниципаль берәмлекләрнең ирекле берләшмәсе булып тора, аның әгъзалары – 50 проценттан артыгы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре.

сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә урнаштырылган айга кадәрге өч ел өчен Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә ярдәм итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре халкының социаль һәм икътисадый проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү саны – кимендә 10 чара.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр алучыларны сайлап алу (алга таба – сайлап алу), субсидияләр алучыларның сайлап алу критерийларына һәм заявкалар керү чиратына туры килүеннән чыгып, тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енә карата субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия

Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы (алга таба – БМО) уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмау;

субсидия алучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмау;

субсидия алучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

субсидия алучы үзгәртеп оештыру (субсидия алучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган.»;

9 пунктта:

беренче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«$а^1$» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$а^1$) заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;»;

«д» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) әлеге Тәртипнең 13 – 17 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре, заявкаларны кабул итмәү тәртибе;»;

«л» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«м» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«н» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

«о» пунктчасында «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Сайлап алуда катнашу өчен субсидия алучы, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән заявкаларны бирү тәмамлану срогыннан соңга калмыйча, Министрлыкка ирекле рәвештә язылган яки әлеге Тәртиптә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләр нигезендә вәкаләтле затның электрон имзасы белән расланган заявканы кәгазьдә яки Министрлыкның рәсми сайтындагы интернет кабул итү аша тапшыра.»;

11 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «финанс-икътисадый» сүзләре алдына «товарларга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр дәрәҗәсе шундый ук товарларга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә уртача базар бәясе дәрәҗәсеннән артмаган» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы һәм җиденче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1нче көненә карата субсидия алучының әлеге Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат.»;

13 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Заявкаларны карап тикшерү максатларында Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссия төзү тәртибе һәм Комиссия турындагы нигезләмә Министрлык боерыгы белән раслана.»;

өченче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

14 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Әгәр заявка сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әгәр заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, ул дөрес дип танылa.

Заявканың сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе хакында карар субсидия алучы тарафыннан заявка составында тапшырылган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә Комиссия тарафыннан кабул ителә.

Сайлап алуда җиңүче дип әлеге Тәртипнең 6 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче булып тапшырылган субсидия алучы танылa.»;

16 пунктта:
беренче абзацта «һәм бәяләү» сүзләрен төшереп калдырырга;
өченче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;
17 пунктта:
беренче абзацта «һәм бәяләү» сүзләрен төшереп калдырырга;
икенче абзацта «заявкасы кабул ителмәгән субсидия алучы турында мәгълүмат,» сүзләреннән соң «заявкалар керү чираты,» сүзләрен өстәргә;
өченче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә, «12» саннарын «14» саннарына алмаштырырга;
бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;
җиденче абзацта «конкурс» сүзен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;
сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;
20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«20. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Министрлык белән сайлап алуда җиңүче арасында, сайлап алу нәтиҗәләре бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешү төзелә.
Бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары Министрлыкка субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп киметелгән очракта, субсидия бирү турындагы килешүгә субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында шарт яки, яңа шартлар буенча бер фикергә ирешеп булмаганда, субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында шарт кертелә.
Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Министрлык тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи. Субсидия бирү турындагы килешүдә үз эченә субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы карала.
Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, субсидия бирү турында килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, субсидия бирү турында килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.
Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә субсидия бирү турында килешү, берьяклы тәртиптә субсидия бирү турында килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган

йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, субсидия бирү турында килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.»;

Министрлык, сайлап алуда җиңүченең сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган яки сайлап алуда җидүче тарафыннан дөрес булмаган мәгүлүмат бирелгән очракта, сайлап алуда җиңүче белән субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарта.

Субсидия алучы, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның субсидия бирү турындагы килешүгә имза куюы тәэмин ителмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.»;

23 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык хисапларны кергән датадан бер эш көне эчендә терки һәм әлеге хисаплар бирелгән көннән алып 15 эш көненнән артмаган срокта тикшерә.»;

$27^1$пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$27^1$. Субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин